КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 апрель г.Казань № 402

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 635 нче карары белән расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасын раслау турында» 2019 ел, 30 июль, 635 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 28 ноябрь, 1083 нче; 2020 ел, 25 февраль, 145 нче; 2021 ел, 1 июль, 530 нчы, 2022 ел, 16 май, 450 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2019 – 2024 елларга Татарстан Республикасында үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) буенча төбәк программасына (алга таба - Төбәк программасы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Төбәк программасының II бүлегендә:

«Үзәкләштерелгән су чыгару системаларының чистарту корылмаларын төзү һәм реконструкцияләү (модернизацияләү) объектлары саны» юлының икенче графасында «15» саннарын «16» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Төбәк программасын финанслау күләме</td>
<td>2019 – 2024 елларда Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 13 016 167,03 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>(мең сум)
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th rowspan="2">Барлыгы акча</th><th colspan="3">Шул исәптән</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</th><th>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</th><th>бюджеттан тыш акча</th></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 728 903,93</td><td>213 168,26</td><td>908 770,0</td><td>606 965,67</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>2 205 814,61</td><td>280 755,74</td><td>1 196 566,48</td><td>728 492,39</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>2 389 460,45</td><td>362 652,52</td><td>1 546 043,15</td><td>480 764,78</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>2 959 538,33</td><td>529 378,26</td><td>2 256 823,09</td><td>173 336,98</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>1 072 719,11</td><td>153 482,21</td><td>654 318,9</td><td>264 918,0</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>2 659 730,6</td><td>406 081,6</td><td>1 731 190,0</td><td>522 459,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>13 016 167,03</td><td>1 945 518,59</td><td>8 293 711,62</td><td>2 776 936,82</td></tr>
</table>
Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

«Төбәк программасының максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>Төбәк программасының максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>Төбәк программасы чараларын тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак сулар күләмен елына 0,04 куб.км га кадәр киметергә, шул исәптән:<br>2019 ел – елына 0,19 куб.км га кадәр;<br>2020 ел – елына 0,18 куб.км га кадәр;<br>2021 ел – елына 0,1348 куб.км га кадәр;<br>2022 ел – елына 0,1348 куб.км га кадәр;<br>2023 ел – елына 0,1348 куб.км га кадәр;<br>2024 ел – елына 0,04 куб.км га кадәр;<br>2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларны чыгаруна елына 0,15 куб.км га кадәр киметүне тәэмин итә торган чистарту корылмалары куәтен арттыруны тәэмин итәргә, шул исәптән;<br>2019 ел – елына 0,0 куб.км га кадәр;<br>2020 ел – елына 0,01 куб.км га кадәр;<br>2021 ел – елына 0,0552 куб.км га кадәр;<br>2022 ел - елына 0,0552 куб.км га кадәр;</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | 2023 ел - елына 0,0552 куб.км га кадәр;<br>2024 ел - елына 0,15 куб.км га кадәр.<br>Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпләп чыгару Төбәк программасының IX бүлегендә китерелгән»; |

Төбәк программасының III бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Төбәк программасы составына «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Россия гражданнарының торак-коммуналь хуҗалыгын сыйфатлы хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру» ярдәмче программасы кысаларында Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гамәлгә ашырылган чара кертелде.»;

Төбәк программасының IV бүлегендә:

егерме җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә:

“14. Әлмәт шәһәре канализациясенең чистарту корылмаларын реконструкцияләү. Чистарту корылмалары норматив чистартылмаган агым суларны агыза, әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган 200 эре объект исәбенә керә. 2018 елдан 2020 елга кадәр чорда 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып ала алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Россия гражданнарының торак-коммуналь хуҗалыгын сыйфатлы хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру» ярдәмче программасы кысаларында агып төшүче суларны механик һәм биологик чистартуның төп блокларын реконструкцияләү, Әлмәт шәһәренең чистарту корылмаларындагы агып төшүче суларны тәүлеккә 40 000 куб метр җитештерүчәнлегe белән суыртү башкарылды.»;

Төбәк программасының VI бүлегенең сигезенче - егерме беренче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак сулар күләмен елына 0,04 куб.км га кадәр киметергә, шул исәптән:

2019 ел – елына 0,19 куб.км га кадәр;

2020 ел – елына 0,18 куб.км га кадәр;

2021 ел – елына 0,1348 куб.км га кадәр;

2022 ел – елына 0,1348 куб.км га кадәр;

2023 ел – елына 0,1348 куб.км га кадәр;

2024 ел – елына 0,04 куб.км га кадәр;

2024 ел йомгаклары буенча Идел елгасына агызып төшерелә торган пычрак суларны чыгаруна елына 0,15 куб.км га кадәр киметүне тәэмин итә торган чистарту корылмалары куәтен арттыруны тәэмин итәргә, шул исәптән;

2019 ел – елына 0,0 куб.км га кадәр;

2020 ел – елына 0,01 куб.км га кадәр;

2021 ел – елына 0,0552 куб.км га кадәр;

2022 ел - елына 0,0552 куб.км га кадәр;
2023 ел - елына 0,0552 куб.км га кадәр;
2024 ел - елына 0,15 куб.км га кадәр.»;
Төбәк программасының VII бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«VII. Төбәк программасын ресурслар белән тәэмин итү

Төбәк программасын финанслауның гомуми күләме 13 016 167,03 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Барлыгы акча | Шул исәптән | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы | җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | бюджеттан тыш акча |
| 2019 | 1 728 903,93 | 213 168,26 | 908 770,0 | 606 965,67 |
| 2020 | 2 205 814,61 | 280 755,74 | 1 196 566,48 | 728 492,39 |
| 2021 | 2 389 460,45 | 362 652,52 | 1 546 043,15 | 480 764,78 |
| 2022 | 2 959 538,33 | 529 378,26 | 2 256 823,09 | 173 336,98 |
| 2023 | 1 072 719,11 | 153 482,21 | 654 318,9 | 264 918,0 |
| 2024 | 2 659 730,6 | 406 081,6 | 1 731 190,0 | 522 459,0 |
| Барлыгы | 13 016 167,03 | 1 945 518,59 | 8 293 711,62 | 2 776 936,82 |

Искәрмә. Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, тиешле бюджетларның мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.»;
Төбәк программасының IX бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Федераль бюджеттан инвестицияләрнең бюджет нәтиҗәлелеген исәпләү

| Рейтингта позиция | Объект исеме | Федераль бюджеттан инвестицияләр күләме, мең сум | Объекттан агызып чыгарыла торган пычрак сулар күләмен киметүнең план буенча күрсәткече, елына мең куб.метр | Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткече мәгънәсе, сум/куб.метр |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Казан шәһәрендәге КБЧК реконструкцияләү (шул исәптән: КБЧК реконструкцияләү Казан шәһәре, 1 нче этап; КБЧК реконструкцияләү Казан шәһәре, 2 нче этап; КБЧК реконструкцияләү Казан шәһәре, 3 нче этап) | 6 134 499,14 | 143 563,84 | 42,73 |
| 2. | Тәтеш шәһәрендә яңгыр сулары канализациясен урнаштыру | 86 342,26 | 454,0 | 190,18 |
| 3. | «Салават күпере» торак районы өчен инженерлык һәм техник | 137 630,5 | 674,3 | 204,11 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | тәэмин итү челтәрләре төзү. Хуҗалык-көнкүреш канализациясе челтәре. 6 этап: Биологик чистарту корылмалары | | | |
| | Васильево штп., 24 мең $м^3$/тәүлек җитештерүчәнлеге, шул исәптән: беренче чират - 12 мең $м^3$/тәүлек кадәр | | | |
| 4. | «Алабуга» СҖТ МИЗ һәм Алабуга шәһәренең районга караган агып төшә торган көнкүреш һәм сәнәгать суларын чистарту корылмаларын реконструкцияләү. I этап | 1 117 406,27 | 5 161,82 | 216,48 |
| 5. | «Алабуга» СҖТ МИЗ һәм Алабуга шәһәренең районга караган агып төшә торган көнкүреш һәм сәнәгать суларын чистарту корылмаларын реконструкцияләү. II этап | | | |
| 6. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Питрәч авылында биологик чистарту корылмалары төзү | 109 959,97 | 401,47 | 273,89 |
| 7. | ТР Зеленодольск муниципаль районының Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогында биологик чистарту корылмалары төзү | 135 746,94 | 365,0 | 371,91 |
| 8. | Яр Чаллы шәһәре, «Замелекесье» торак районы. Яңгыр сулары канализациясе | 162 101,06 | 390,0 | 415,64 |
| 9. | Минзәлә муниципаль районының Юртово бистәсендә биологик чистарту корылмалары төзү | 18 600,43 | 27,4 | 678,85 |
| 10. | ТР Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр тибындагы поселогында чистарту корылмалары төзү | 115 867,64 | 169,0 | 685,61 |
| 11. | Казан шәһәренең Ветеринария академиясе районындагы су объектларына яңгыр сулары канализациясе чыгу юлларында җир өстеннән агып төшә торган суларны чистарту корылмалары төзү | 70 229,22 | 97,0 | 724,01 |
| 12. | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авылында биологик чистарту корылмалары төзү | 42 915,36 | 54,75 | 783,84 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| 13. | ТР, Зәй муниципаль районы, Поповка авыл җирлеге, Зәй шәһәренең чистарту корылмаларын төзү | 65 467,06 | 29,66 | 2 207,25 |
| 14. | Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кощаково авылында биологик чистарту корылмалары төзү | 96 945,77 | 12,5 | 7 755,66 |
| | Барысы | 8 293 711,62 | 151 400,74 | |

Чараларны гамәлгә ашыру чираты проект-смета документациясе булуны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының проект-смета документациясен эшләүгә акча бүлеп бирү турында боерыгы булу һәм аны һәр тормышка ашыру елына Төбәк программасының максатчан күрсәткечләрен үтәү кирәклеге исәпкә алынып билгеләнде.»;

Төбәк программасының X бүлегенең беренче - җиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2019 - 2024 елларда Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесен су чыгаруның үзәкләштерелгән системасы объектларын төзүгә, модернизацияләүгә һәм (яисә) реконструкцияләүгә каралган финанс чаралары күләме бюджеттан тыш акчалар исәбеннән 2 776 936,82 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 елда - 606 965,7 мең сум;

2020 елда - 728 492,39 мең сум;

2021 елда - 480 764,78 мең сум;

2022 елда - 173 336,98 мең сум;

2023 елда - 264 918,0 мең сум;

2024 елда - 522 459,0 мең сум.»;

Төбәк программасына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 3 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 4 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Төбәк программасына 5 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин